ДОКЛАД НА КОНФЕРЕНЦИИ

# ХӨРМӘТЛЕ КОНФЕРЕНЦИЯ ДЕЛЕГАТЛАРЫ, КУНАКЛАР ҺӘМ ЗАЛДА УТЫРУЧЫ ЯКТАШЛАР!



**Сезне бүгенге җыелыш уңаеннан барыгызны ды чын күңелдән тәбриклим!**

Безнең бүгенге җыелуның сәбәбе район татар милли-мәдәни мөхтәриятенең 3 еллык эшенә бәя бирү һәм алдагы елларга план кору

Бүген үзенә күрә бу җыелыш безнең төньяк-көнбатыш регионының татар курултае сыманрак тоела. Шуңа да бүгенге сөйләшү, фикер алышулар җитди приниципиаль төс алыр дип ышанам.

Безнең татар оешмасы неформально 20 елдан артык санала. Ә инде 1994 елдан закон буенча теркәлеп эшли башлады.

Район татар иҗтимагый үзәгенең беренче рәисе Мәсгуть абый Галяутдинов чын татар рухы белән сугарылган кеше безнең оешмага үрнәк булырлык нигез салып калдырды. Ул җитәкләгән чакта мәктәпләрдә татар теле укытуга игътибар көчәйде. Татарстаннан китаплар кайтарыла башлады һәм татар оешмасы үзенә күрә методика үзәк формасына әйләнде туган телне саклап үстерүдә.

Мәсгуть Гильмутдинович татар иҗтимагый үзәгенең эшен советтан тыш мәдәният хезмәткәрләре, балалар бакчасы тәрбиячеләре, татар теле укытучылары, китапханә хезмәткәрләре белән берлектә алып барды.

Менә шулай тыгыз элемтәдә киңәшеп эшләгәндә генә, безнең район милли-мәдәни мөхтәриятенең эшен алга таба тагы да ныграк җанландырырга була, туган телебезне, гореф — гадәтләребезне саклап үстерүдә.

1998 елда безнең татар оешмасы милли-мәдәни мөхтәрият исемен алды. Исем алынуын алынды, ләкин эшләр Мәсгуть абый сызган юлдан бераз тайпылыш алып, киң җәмәгатьчелек читтәрәк торып торды. Ә бит оешма русча әйткәндә, «общественный», дип атала. Шуңа күрә, монда чын демократия, теләктәшлек, халыкара дуслык белән үрелеп барырга тиеш эшләр.

Без районда күпсанлы халык булсак та, башкаларга үрнәк булып, барысы белән дә дус яшәргә тиеш. Татар халкының канында ул дуслык хисе һәм бу татар оешмасы эшләрен татар рухлы, үзенең телен, гореф — гадәтләрен хөрмәт иткән, башка халыклар белән дус булган кешеләр алып барырга тиеш. Бүген сайланачак яңа советка теләкләр шул.

2007 елда мине безнең татар оешмасының рәисе итеп сайладылар. Беренче максат итеп мөхтәрият зур авылларда первичный оешмалар булдырды. Бу эш район буенча булган татар халкын җыеп, аларга таянып эш башкарырга кирәк иде. Мөхтәрият ишеге теләгән бөтен кешегә дә ачык. Татар конгрессы белән дә элемтә җанланды, ешайды. Оешманың эшен район газета битләрендә дә яктырттык һәм шулай ук үзебезнең газета «Туган як»та булдырылды. Бу газетада күрше район татарларының яшәеше дә яктыртыла.

2008 елда газета теркәлде, ә 2009 елдан почта аша яздырып алу мөмкинлеге булды. Елгә аена 2 тапкыр чыга. Мәкаләләр татар һәм рус телендә басыла.

Өлкәнең бу як төбәгендә 6 районда 37 меңнән артык татар яши. Күбесе бердәнбер татар гәзите «Яңа вакыт»ны ала. Ләкин аралар ерак булу сәбәпле, безнең якның тормышы бик сирәк языла. Шуңа «Туган якның» булуы бик әһәмиятле безгә.

«Туган якның» битләрендә укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, хезмәт ветераннары чыгышлар ясыйлар. Киләсе саннарда балаларыбыз да туган телләрендә язмалар бастырсалар, бик күңелле күренеш булыр иде. Бу мәсьәләне чишәргә бигрәк тә татар теле укытучылары һәм китапханәчеләр ярдәм итсәләр, яхшы булыр иде.

Татар рухын саклауда, уятуда мәдәни чараларның әһәмияте бик зур. Татар автономиясе хезмәткәрләре, китапханәчеләр белән берлектә, бу юнәлеш буенча махсус план төзеп, эш алып бардык. Халык күңелендә тиешле урын алган фестивальләр үткәрелде. Аларның берсе «Ак хисләр» — быел алтынчы тапкыр уздырылды. Бу фестиваль-конкурс районда башланып, хәзер төбәкара уздырыла. Менә ике ел инде Самара өлкәсе Гали авылы белән дә элемтә урнаштырылды. Бу ике як бер берсенә барып, бергә матур мәдәни чаралар үткәрәләр. Мәсәлән, бөек Тукаебыз иҗатына багышланган һәм «Мин бит татар баласы» дигән конкурслар безнең балаларның, яшьүсмерләрнең күңелләре бердә туган теленнән, туган мохитеннән читләшмәгәнне күрсәтте. Тик алар белән җаен табып эшли белергә генә кирәк. Бу безнең халкыбыз, туган телебезне саклауда булган изге бурычыбыз. Без бу бурычны үтәргә тиешбез.

2007 елда махсус балалар өчен «Алтын көз» исемле төбәкара фестиваль — конкурс оештырылды. Анда балалар бакчасы һәм 15 яшькә кадәр булган мәктәп балалары катнаша.

Бу фестиваль-конкурслар балаларыбыз һәм яшьләр күңелендә үзенең туган теленә, җыр-моңга, татар халкының гореф-гадәтләренә карата зур ихтирам уята. Алда да бу эшкә әһәмият биреп номинацияләрне арттырырга кирәк дип уйлыйм. Быел менә Котлымбәт авылыннан татар күлмәкләре белән мәктәп кызлары чыгыш ясадылар һәм фестивальнең иң зур бүләген — Гран-прины алып киттеләр. Бу номинациягә ике фестивальгә да кертергә кирәк. Мәктәптә тегү эшләре керә дәрес булып. Менә шул дәресләрдә матур күлмәкләр тегеп кисәләр, костюмнар юк дип, йөрмәсләр иде.

Туган телебезне саклауда әлбәттә, татар теле укытучыларының йогынтысы зур. Әгәр дә алар бу эшне чын күңелдән акча өчен түгел, булсын өчен эшләсәләр, телебез югалмаячак. Әлбәттә, ата-аналарның да роле зур бу эштә. Гаиләсендә туган телгә ихтирам булса, чит ил татарлары үрнәгә буенча өйдә үз-ара балалары белән татарча сөйләшсәләр, милләт сакланачак.

Уйланасы һәм алдагысы көндә бу өлкәдә эшлисе эшләр күп. Мәктәптә бу эшкә тиешле урын булмаса, әйдәгез китапханәләрдә, мәдәният йортларында өстәмә чаралар булдырыйк. «Туган тел» клубы эшләрен киңәйтик. Безнең район мәдәният хезмәткәрләренең, китапханәчеләрнең күбесе татар җанлы, татар рухын чын мәгънәсендә саклаучылар.

Мәдәни чаралар әлбәттә финанс чыгымнарсыз үтми. Бу эштә безнең уңган егетләребез дә кулларыннан килгән кадәр ярдәм итәләр. Шуларның берсе Ришат Галимов. Аның быел юбилей елы — аны барыбыз да тәбрик итик. Аңа уңышлар, исәнлек, гаилә бәхете телик!

Мәдәни чаралардан татар халкының иң мәртәбәле бәйрәме — «Сабантуй» безнең районда зур әзерлек белән уздырыла. Күрше Абдуллин районында да депутат буларак, бу халкыбызның олы бәйрәмен оештыруда, ярдәм күрсәтергә туры килде. Хәзер анда яшәгән башка милләтләр арасында да бу бәйрәм үзенең данлы урынын алды.

Безнең оешма ел саен балаларны Татарстан лагерьларына ялга җибәрә. Теләгән кеше алдан заявка бирә, ә кайбер балаларга льготалы кызыксындыргыч бүләк юллама да әзерлибез. Монда инде яхшы укучылар һәм аз мөлкәтле гаилә балалары керә.

Безнең автономия тагын бер әһәмиятле эш башкарды. Безнең инициатива белән 3 татар оешмасы ассоциация төзеде, исеме «Бердәмлек». Монда Әсәкәй татар мөхтәрияте һәм Гали авылы, Бугуруслан шәһәре «Туган тел» оешмалары керде. Бергә планнар төзеп, төрле мәдәни чараларны бер-беребезгә барып үткәрәбез. Бу үзе уңай йогынты ясый туган телебезне саклауда, мәдәниятебезне үстерүдә. Бик әһәмиятле эш дип саныйм үзебезнең мәртәбәле татар шәхесләре белән очрашуларны. 3 ел эчендә күренекле язучылар Резеда Вәлиева, Нәзифә Каримова белән тирән эчтәлекле мәдәни чаралар уздырылды. Әсәкәй, Колшәрип һәм Солтангол авылларында шулай ук мәктәп балалары алдында чыгыш ясадылар алар.

Ә Татарстанның Халык артисты Миңгол Галиев белән безнең «Ак хисләр» фестивале башланып, дәвам итә 6 ел буена.

Бу чараларны башлап, оештырып, алып баручылар район мәдәният йорты хезмәткәрләре, мөхтәрият эшендә актив катнашучылар.

Халкыбызның рухын саклап киләчәк буыннарга җиткерү эшендә дин әһелләренең роле бик зур. Мәчетләрдә, муллалар теләгән балаларга дин дәресләре биреп, аларда үз халкына аның гая тарихына ихтирам уяталар. Бу өлкәдә имам Илдар хәзрәт Багаутдинов Әсәкәй мәчетендә дин дәресләре оештыра. Район мәчетләрендә халкыбызның мәшһүр бәйрәмнәре Ураза, Корбанны ел саен өлкән буын кешеләрен җыеп бәйрәм ашларын үткәрергә булышабыз. Һәр мәчеткә сарык биреп өстәлгә сый-нигъмәт алабыз.

Район мөхтәрият, мәдәният йортлары белән берлектә татар халкының элеке йолаларын, бәйрәмнәрен өйрәнеп якташларына күрсәтү өстендә эшли. Шуларның берсе Нәүрүз бәйрәме. Бу бәйрәм йолаларын фольклор ансамбле «Чишмә», төрле төбәкләрдә районнан тыш та күрсәтә.

Мөхтәрият чыгымнарын финанслауда Әсәкәйнең татар җанлы спонсорлары Хәйдәр Хабиров, Рөстәм Гилязов, Рәвкәт Фахретдинов һәм башкалар ярдәм итәләр.

Район мөхтәрият эшенә бүген бәя бирер алдыннан, хөрмәтле милләттәшләр, сезнең киңәшләрегезне, сорауларыгызны ишетербез. Сезнең киңәшләрегез алдагы планнарында яңа совет әһәмиятле урын бирер дип уйлыйм.

Рәхмәт игътибарыгызга!